КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 март г.Казань № 350

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2000 ел, 21 июнь, 436 нчы; 2006 ел, 27 апрель, 211 нче; 2006 ел, 15 июнь, 303 нче; 2006 ел, 17 июль, 366 нчы; 2008 ел, 25 июль, 536 нчы; 2009 ел, 30 март, 192 нче; 2009 ел, 25 май, 333 нче; 2009 ел, 24 декабрь, 879 нчы; 2011 ел, 23 май, 404 нче; 2011 ел, 21 декабрь, 1027 нче; 2012 ел, 06 февраль, 86 нчы; 2012 ел, 17 июль, 605 нче; 2012 ел, 20 декабрь, 1110 нчы; 2013 ел, 31 май, 367 нче, 2017 ел, 14 гыйнвар, 7 нче, 2017 ел, 13 сентябрь, 668 нче, 2019 ел, 17 декабрь, 1159 нчы, 2022 ел, 27 декабрь, 1427 нче, 2023 ел, 25 февраль, 184 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге юллардан соң

| | |
|---|---|
| «Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 3 пункты нигезендә бирелгән һәм Россия Федерациясе | 0,1» |

| | |
|---|---|
| Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 25 пункты нигезендә яисә «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре белән чиктәш чиге булган җир кишәрлекләрендә төзелгән объектларга (төзелеш чорын да кертеп) | |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган табигать территорияләре белән идарә итү буенча юридик затка тапшырылган Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасы нигезендә арендага бирелгән җир кишәрлекләрендә экологик туризм өлкәсендә ял һәм рекреация объектларына (төзелеш чорын да кертеп) | 0,1»; |

түбәндәге юллардан соң

| | |
|---|---|
| «Спорт объектлары һәм корылмаларына (төзелеш чорын да кертеп) | 0,17» |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Әлеге Исемлектә башкасы каралмаган булса, юридик затка Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктның 3 пунктчасы нигезендә арендага бирелгән җир кишәрлекләрендә ял итү һәм экология туризмы өлкәсендә рекреация объектларына (төзелеш чорын да кертеп) | 5 % |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин